| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>Совет Шарлиареминского сельского<br>поселения Сармановского муниципального района | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районы<br>Шәрләрәмә авыл җирлеге советы |

РЕШЕНИЕ КАРАР

2016 ел, 1 февраль № 18

.

Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 ст. 1 п., Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставының 11 ст. нигезендә Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Советының 2016 елның 25 гыйнварында кабул ителгән карары нигезендә № 16 «референдум үткәрү инициативасы турында», Шәрләрәмә авыл җирлеге Советы хәл итә:

1. 2016 елның 20 мартына Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2016 елда Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, 200 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүегез һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүегез белән килешәсезме?:

- каты коммуналь калдыкларны җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыруда катнашу;
- җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны төзекләндерү;
- җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыру;
- җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру;
- җирлек территориясен төзекләндерү (урамнарны яктырту, территорияләрне яшелләндерү, кече архитектура формаларын урнаштыру һәм карап тоту); ;.

«ЮК» «ӘЙЕ».

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Хуҗина